# Мәүлүд Кыйссасы

Запись Масгуды Шамсутдиновой



http://sub.tatars.com/articles/TAT/256/

Дин кардәшләр сөенеч сезгә, шатлык тулсын йөзегезгә,
Нур балкысын йөзегезгә, изге Мәүлид ае туды.

Хак рәхмәте безгә бик зур, җирне күкне каплады нур,
Ачты безгә туры хак юл, изге Мәүлид ае тугды.

Шушы айда Рәсүл туды, дөньяда нур балкып торды,
Күңелләргә шатлык тулды, изге Мәүлид ае туды.

Бу ай безгә бик зур бәйрәм, дөньяга ул бирде бер ямь,
Хөрмәт ит син күңел белән, изге Мәүлид ае туды.

Кадерле ай бу ай безгә, иман нуры бирде йөзгә,
Бу Аллаһыдан бүләк сезгә, изге Мәүлид ае туды.

Изгелек кыйл – бәхтең артыр, синнән иман нуры балкыр,
Тәүбәң кабул булып кайтыр, изге Мәүлид ае туды.

Иман әһлен шатландырган, туры юлга сафландырган,
Начар эштән сакландырган изге Мәүлид ае тугдый.

Аллаһ дусты алып килгән, мөэминнәргә шатлык биргән,
Һәр ел саен хөрмәт күргән изге Мәүлид ае тугдый.

Рәсүл исме – ислам җаны, күкрәгеңдә сакла аны,
Кушканнарын аның тагы. Изге Мәүлид ае тугдый.

Баштан аяк рәхмәт булган, мөэминнәргә куат булган,
Хакдин бик зур нигъмәт булган изге Мәүлид ае тугдый.

Бу ай бөтен айдан өстен, һәркем ихлас хөрмәт итсен,
Хөрмәтләрдән савап көтсен, изге Мәүлид ае тугдый.

Котлы булсын ислам әһле, шатлык сезгә иман әһле,
Сөенеч сезгә иман әһле, изге Мәүлид ае тугдый.

©